СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

25 апрель, 1997 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 45 (8057) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Иртәгә, 26 апрельдә - шимбә өмәсе

**Яз бәйрәме - 1 нче Майга әзерлек уңаеннан шәһәрне төзекләндерү һәм санитар чистарту уңкөнлеге кысаларында иртәгә, 26 апрельдә Норлатта һәм авыл торак пунктларында шимбә өмәсе игълан ителде.**

**Үзебезнең эш урыннарын һәм торак пунктларны тәртипкә китерү - һәммәбезнең дә уртак эше.**

### Район хакимиятендә

## Иртәгәне бүгеннән кайгырт

Районның авыл хуҗалыгында башланган реформацияләү - бер генә көндә башкарыла торган эш түгел. Аның ахыр нәтиҗәсе ул эшнең башында нинди кадрлар торуына да хәлиткеч дәрәҗәдә бәйле булачак. Шуңа күрә дә район хакимияте иртәгә авыл хуҗалыгына киләчәк белгечләрне бүгеннән үк якыннан белеп тору, аларның киләчәктә үзләре эшләячәк хуҗалыклар белән якыннан таныш булуына ирешү һәм, иң мөһиме, аларның бүген районда башланган киң колачлы реформацияләү эшенең хәзердән үк үзәгендә кайнап, аның асылына төшенүләре турында кайгырта. Безнең районнан Чистай совхоз - техникумында укучы студентлар белән хакимияттә очрашып сөйләшү дә нәкъ әнә шул максатны күздә тотып оештырылды. Хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев һәм авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ә.Н.Рәхмәтуллин яшь кадрларны район агропромышленностенда башланган реформацияләүнең асылы, төп юнәлешләре һәм аның ахыр максатлары белән таныштырдылар, киң колачлы ул зур эшләрне башкарып чыгуда яшь, инициативалы һәм энергияле белгечләргә зур өмет баглануын әйттеләр. Нәкъ менә шул нияттән, киләчәктә дипломлы техник - механик булачак ул студентлар ( ә безнең районнан ул техникумда 25 кеше укый) практикага да районның реформалаштыру эше иң кыю башланган хуҗалыкларына җибәрелделәр. Тормышларының яңалык язына туры килгән зур сынавын уңышлы үтүләрен генә телисе килә.

## Зур сынаулар язы

**Елның бер генә фасылы да гел уңайдан гына килеп тормый. Шул исәптән быелгы язның озаккарак сузылырга мөмкин булуы турындагы фаразлар да өлешчә раслана. Әмма бердәм булып кырга чыккач кына ешаеп киткән яңгырлар игенчеләребезне һич тә борчырга тиеш түгел. Явымнарның болары әле җиргә бик кирәкле дымны арттыра гына. Шулай да тезгенне бушатырга да һич ярамый. Алда торган язгы кыр эшләрен көннәр утырып киткәч тизрәк тоту өчен бүгеннән башкарасы эшләр дә бихисап. Газетабызның өченче битендә урнаштырылган тәфсилле язмада нәкъ менә шулар хакында сүз бара. Аны игътибар белән укып чыгу бүген кыр эшләренә кагылышы булган берәүгә дә зыянга булмас дип уйлыйбыз.**

## Оешканлык белән

**«Үрнәк» крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциациясеннән Исхак Шәйхиев хәбәр итә.**


- Хуҗалык язгы кыр эшләренә зур оешканлык белән кереште. Беренче бригадада ике агрегат күпьеллык үләннәрне тукландыру башланды. Икенче бригада механизаторлары да беренче көннәрдән үк алдырдылар. Уҗым арышы тамырдан тукландырыла, өстәп чәчү үткәрелә. Бу эштә ДТ - 75 тракторларын йөртүчеләр Касыйм Рәхмәтуллин һәм Рифкать Миннеголов өлгерләр. Миннехан Мостафин, Касыйм Хуҗәхмәтов, Гомәр Вафин, Әмир Шәйдуллин булышалар аларга. МТЗ - 80 тракторчысы Нәфис Шәфигуллин исә агрегатларны ашлама белән тәэмин итеп тора. Рөстәм Шәвәлиев, Валентин Любимов, Дамир Ханов ашламаны ваклап, тракторларга төяп торалар.

## ҖАВАПЛЫ КӨННӘР БУ

Киекле кооперативлар ассоциациясендә эшнең иң тыгыз көннәре иде. Бердән, хуҗалык язгы кыр эшләренә чынлап торып керешеп килсә, икенчедән, әле кичә генә өч кооперативлар ассоциациясе булып эшләгән хуҗалык күршеләре - «Чишмә» КХАсы белән берләштерелде. Шулай итеп, кыр эшләренә Киекле КХАсы 6 мең гектар җирле зу - ур хуҗалык булып аяк басты. Хуҗалык рәисе Н.Ш.Шарапов - Әнә хәзер үзе кыр эшләрен күзәтеп - оештырып йөри, үзе кешеләр белән таныша. Кизләүдә күпьеллык үләннәр туклындыруда эшләүче Фаиз Бильданов белән дә эш арасында сөйләшеп алдылар. Ә Киекледә эш тулы колачта бара. Икенче кооператив җитәкчесе Хафиз Зәйнетдинов эшнең башлангыч чорыннан канәгать. Әнә Наил Хәйбуллин абыйсы Назыйм белән бергә уҗымнарны өстәп чәчәләр. Сүз уңаеннан, уҗымнар зәгыйфь кышлаган, аларны тулысынча диярлек өстәп чәчәргә туры киләчәк.



(Ахыры 2 нче биттә).



**Рәсемнәрдә: механизатор Әнәс Вафин, агрегат эшкә әзерләнә.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

### Рәсми хроника

## Рәис алышынды

20 апрельдә «40 лет Победы» КХАсы эшчәннәренең гомуми җыелышы булды. Җыелыш ассоциация рәисе Ш.Ш.Төхфәтуллинның аны вазифаларыннан азат итү турында гаризасын канәгатьләндерде. «40 лет Победы» КХАсы рәисе итеп **РАСЫЙХ КАИМОВИЧ СӘМИГУЛЛИН** сайланды.

## Тагын ике дипломант

Узган шимбәдә Казанда үткән Урта Идел буе халыкларының традицион халык коралларында уйнаучыларның йомгаклау смотр - конкурсында безнең районнан мандолиначы Адлер Газизуллин һәм курайчы Бибинур Әбделвәлиева катнаштылар һәм икесе дә дипломант исеменә лаек булдылар.

Без, райондашлары әлеге үзешчәннәрне кайнар котлыйбыз.

## ЧИСТАЛЫК АЙЛЫГЫ БАРА

**Апрель кояшының җылы нурлары кар көртләрен эретте, һаваны җылытты һәм... озын кыш буена җыелган чүп - чар, көнкүреш калдыкларын ачып салды. Байтак коллективлар апрель өмәсен көтмичә, эш көне азагында көрәкләр, себеркеләр, чиләкләр тотып шәһәр һәм үзләренең промышленность базалары территорияләренә чыгалар. Бу эш ничек оештырылган? Безнең бу соравыбызга дәүләт санэпидкүзәтү үзәге баш табибы И.В.ӘНДӘРОВ менә нәрсәләр хәбәр итте:**

- Узган атнада НГДУ, шикәр заводы, элеватор, нефтебаза, тимер юл ОРСы, азык комбинаты территорияләрен җыештыру буенча эш яхшы оештырылган иде. Агач складны, СПТУ, 53 нче СМУда бу эш тиешле дәрәҗәдә үткәрелмәде.

Бүгенге көнгә шәһәрнең барлык йортлары территорияләренең дә санитар торышлары начар - бу эшкә акрын керештеләр. Анда яшәүчеләрне дә бу чарага тартырга кирәк. МПП, шикәр заводы, МСО торак - коммуналь оешмалары, 30 нчы йортлар идарәсе, «Сельхозтехника», «Агрохимсервис», машина төзү заводы, сөт - май комбинаты, ДРСУ, райпо һәм башкалар җаваплы бу эш өчен.

Безнең шәһәрдә, аеруча аның кырыйларында законсыз чүплекләр бик күп. «Агрохимсервис», подстанция, хәрбиләштерелгән янгын бүлеге районнары, МСО һәм тимер юл микрорайоннары арасында алар. Шәхси йортлар һәм кайбер предприятиеләр озак еллардан бирле чүпләрен шунда түгәләр. МПП җитәкчелегенә бирегә чүп җыю контейнерлары куярга, ә предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә аны бары тик шәһәр чүплеге территориясенә генә чыгарырга рөхсәт итәргә кирәк.

«Вторчермет», 53 нче СМУ, СПТУ, ОСТО район Советы кебек оешмаларның промышленность базаларының пычрак хәлдә булуын да әйтәсем килә. МСО, райпо, МПП, АТП, сөт - май комбинаты, «Сельхозтехника» һәм СПТУ үзләренә беркетелгән территорияләрен тулысынча чистартып бирүне тәэмин итмәделәр.

Шәһәр, промышленность базалары, шулай ук җирле үзидарәләр территорияләрендә тиешле санитар тәртип булдыру максатында район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин 16 апрельдән 16 майгача санитар чистарту буенча айлык игълан итте. Шул ук документ белән предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләргә урамнар һәм территорияләр беркетелде. Айлык чорында, шулай ук киләчәктә дә карарда билгеләнгән таләпләрне тулысынча тормышка ашырырга кирәк. Бу - мәҗбүри һәм даими санитар көннәр, көнкүреш калдыкларын һәм чүпләрне үзвакытында чыгару һәм чистарту, тәртип булдыру буенча башка чаралар үтәү МПП директоры Ә.К.Гайнуллиннан махсус машиналар паркын файдалануны яхшырту, аның эшен ике сменада оештыруны таләп итәчәк. Урыннарда җирле үзидарә Советлары рәисләренә авылларда чүплекләр оештыру, ә хәрәкәттәгеләрен тиешле тәртипкә китерү бурычы йөкләнәчәк.

Шулай итеп, бурычлар куелды һәм аларны үтәргә кирәк. Безнең шәһәребез һәм авылларыбыз төзекләндерү, тәртип булдыруга мохтаҗ. Бу - безнең уртак йортыбыз һәм аның чисталыгы турында кайгырту да безнең уртак бурычыбыз.

## Суган үстерегез, сатыгыз

### Сорагыз: җавап бирәбез

*«Мин авылда яшим. Җитмешенче еллар азагыннан алып төп керемем яшелчә бакчамнан - суган үстереп сатам. Баштарак бу эш бик отышлы иде. Соңгы елларда үстергән суганны тапшыру, сату кыенлашты. Никтер райпоның хәзерләүләр конторасы күп итеп кабул итми аны. Югыйсә районда, республикада суганга ихтыяҗ да зурдан инде.*

***Ф.ВӘЛИЕВ».***

**Бу хат белән без райпо идарәсе рәисе М.С.Моратовны таныштырдык. Түбәндә аның җавабын урнаштырабыз:**

- Хат авторы хаклы. Соңгы елларда безнең хезмәт тарафыннан суган хәзерләүгә әһәмият җитди кимегән иде. Әмма быелдан моңа игътибар артачагын бүген үк кистереп әйтә алам. Шул максатта быел хәзерләүләр конторасына суган орлыгын да җитәрлек кайтарттык. Аны кулдан акча түләп, шулай ук көзен суган тапшыру шарты белән килешү нигезендә дә алу мөмкин.

Быел хәзерләүләр конторасы 5 мең тонналап суган хәзерләүне планлаштыра. Август азагында ук керешәчәкбез без бу эшкә. Суганны иң беренче чиратта Октябрь районында яшәүчеләрдән кабул итәчәкбез.

Райондашларыбызны ышандыра алам: суган чәчегез, үстерегез. Ә без, үз чиратыбызда, аны сездән кабул итеп алып, үзвакытында исәп - хисап үткәрүне гарантиялибез.

# ҖАВАПЛЫ КӨННӘР БУ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Агалы - энеле Хәйбуллиннар янәшәсендә икенче - Илсөяр Гыйльманов белән Радик Габделганиев агрегаты да бик җитезләр. Дым каплатуда 6 агрегат эшли. Азат Әхмәтвәлиев, Рафик Шәрәпов агрегатлары биредә хезмәтне әйдәп баралар. Бүген - иртәгә җирләр чәчү өчен дә өлгерәчәкләр. Әүвәл арпа, аннан борчак җиренә агрегатлар төшерергә әзерләнәләр. Әлбәттә, җиргә инкрустацияләнгән орлык күмдереләчәк, ашлама белән чәчеләчәк. Басудагыларга ашламаны пенсионер Тәлгать Мөхәммәтов ГАЗ - 53 машинасы белән чыгарып тора, өзеклекләр тудырылмый. Ындыр табагында Шәяхмәт Хәсәншин җитәкчелегендә хатын - кызлар орлык агулыйлар. Эшне шулай комплекста алып баруны таләп итә чәчү чоры. Беренче кооператив җитәкчесе Илгиз Сафиуллин да эшне шулай оештырырга тырыша. Әнә уҗым арышын арпа белән өстәп чәчүдә ике Касыйм Шәрәпов һәм Әнәс Вафин агрегатлары эшли. Аңа кадәр 60 гектарда күпьеллык үләннәрне тукландырырга өлгергән иделәр. Тәҗрибәле механизаторлар кооперативта төп чәчү эшләрен алып барачаклар. Бу уҗым кырын тәмамлауга янәшәдәге 90 гектарлы сабан бодае басуына күчәчәкләр. Басулар тиз өлгерә, ут булырга, җитез булырга кирәк. Шуңа дым каплату эшен төнге сменада оештырачаклар.

Киекледә шундый бердәмлек, омтылыш бүген. Шөкер, басуга чыгасы техника тулысы белән әзерләнде. Бу мәсьәләдә шефлары - Норлат автоюллар идарәсенең ярдәмен дә шактый тойдылар алар. 3 ашлама төягечнең берсен алар ясап бирделәр, ягулык - майлау материаллары белән дә булыштылар. Җиргә өстәмә минераль сыйны да байтак әзерләгән иделәр киекleләр, инде хуҗалыклар кушылгач азотлы ашлама кайтару мәшәкате белән йөриләр. Әле телгә алынган ике кооперативта да игенчеләр өчен ризык кыр кухнясында әзерләнә, 3 тапкыр ашату оештырылган, механизаторлар аның сыйфатыннан да, бәясеннән дә канәгатьләр. Иң мөһиме - хәзер алган темп, оешканлыкны киметмичә, бердәм булып чәчүне кыска срокларда очлап чыгарга - шуннан да кадерлесе юк алар өчен. Игенченең иң җаваплы, иң киеренке көннәре шулай үтә Киекледә.

С.НУРУЛЛИНА.

## Артып калса - акча эшлә!

**Шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу барышы. Мәгълүматлар 1997 елның 21 апреленә.**

Саннарның беренче баганасы -җирле үзидарә Советлары исемнәре, икенчесе - 1997 елның 1 яртыеллыгына задание, өченчесе - барысы сатып алынган, дүртенчесе - 1996 елның шул көненә сатып алынган(центнерларда), бишенчесе - бер сыерга узган елгыдан артык яки ким (килограммнарда)

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Андреевка | 274 | 43 | 13 | + 26 |
| Богдашкино | 278 | 59 | 11 | + 44 |
| Киекле | 1026 | 304 | 131 | + 46 |
| Иске Чаллы | 980 | 273 | 55 | + 47 |
| Яңа Иглай | 984 | 324 | 102 | + 56 |
| Кормыш | 1163 | 352 | 90 | + 59 |
| Урта Камышлы | 707 | 326 | 66 | + 89 |
| Егоркино | 852 | 208 | 125 | + 23 |
| Якушкино | 668 | 122 | 64 | + 21 |
| Биләр Озеро | 599 | 90 | 35 | + 23 |
| Бикүле | 530 | 161 | 175 | + 37 |
| Гәйтән | 730 | 157 | -- | + 52 |
| Фома | 929 | 125 | 94 | + 9 |
| Мамык | 418 | 21 | 177 | - 92 |
| Сәләнгеш | 446 | 340 | 109 | + 127 |
| Елаур | 666 | 93 | 55 | + 17 |
| Тимерлек | 341 | 41 | 42 | + 3 |
| Иске Әлмәт | 600 | 224 | 117 | + 44 |
| Кычытканлы | 479 | 373 | 85 | + 149 |
| Әмзә | 649 | 402 | 167 | + 91 |
| Колбай Мораса | 644 | 323 | 193 | + 45 |
| Заречный | 502 | -- | -- | -- |
| Төрнәс | 512 | 135 | 45 | + 46 |
| Чулпан | 529 | 473 | 43 | + 215 |
| Тумба | 214 | -- | -- | -- |
| Түбән Норлат | 780 | 137 | -- | + 43 |
| **Район буенча** | **16500** | **5106** | **2067** | **+459** |

***

Мәгълүматлардан күренгәнчә, шәхси сектордан сөт җыю узган елгы шул чор белән чагыштырганда байтакка әйбәтрәк бара. Әмма Андреевка, Мамык җирле үзидарә Советларына бу эшне активлаштырасы бар әле. Хәзер сөт җыю өчен иң кулай вакыт башланды. Халыкның артып калган продукциясе аңа өстәмә керем бирсен, моның өчен сөт җыюны нәтиҗәле оештыру, аңа түләүне вакытында башкару һәр төбәктә күз угында булырга тиеш.

## «Кондырча» унганнары

Бер коллективта булса да булыр икән шул кадәр унган, тырыш, булдыклы хатын - кызлар. Кайсын гына алсаң да мактап туймаслык бит. Әнә Гөлфия Вәлиева 28 еллап сыер сава,терлекчелекнең мәшәкатьле хезмәтен җыр җырлагандай күңел багълап башкарып килә. Яки Галия Әбделмәнова. Өендә дә, эшендә дә шулкадәр зур йөкне тартырга ничек өлгерә диген аны! (Юкса, иптәше Рафик та иртә таңнан Галия белән үк шул ук фермага эшкә чыгып китә бит). Әле ничек кенә өлгерә: узган елны ул хуҗалыкта икенче зур күрсәткечкә ирешеп тәмамлаган иде, быелның 3 аенда да продукция җитештерүдә алдынгы сафта.

Әсия Вәлиева да унганлыкта хезмәттәшләреннән калыша торганнардан түгел. 7 ел эшләп, үз хезмәтенә һич тел - теш тидермәде.

Чамалыйсыздыр: сүз - «Кондырча» КХАсы товарлыклы - сөтчелек фермасы унганнары турында бара. Быел да алар продукция җитештерү буенча район лидерлары исәбендә. Хәзер биредә һәр сыердан көнгә 17,8шәр килограмм сөт савалар. Коллективта исә иң мул сөтне беренче кат бозаулаган сыерлар бирә: әнә 30 еллык савучы Минсара Бакирова группасындагы һәр малдан 21,7әр кг. сөт сава. Менә шуңа да ничек сокланмыйсың ди инде бу коллективка?! Булса да булыр икән бу кадәр унганнар!



**Рәсемдә: «Кондырча» КХАсы савучылары А.Вәлиева, Г.Әбделмәнова, Г.Вәлиева.**

## ҺӘРКЕМ ҮЗ УРЫНЫНДА

Хезмәт коллективларында

Нефтьче һөнәрен сайлаганда һәркем аңа гаҗәеп кырыс шартларда эшләргә туры киләчәген аңлап эш итәргә тиештер, мөгаен. Чөнки төп хезмәт урыны, шулай ук өйрәнү, тәҗрибә туплау да шунда яңгырда, карлы буранда, җәйге челләдә ачык һавада үтәчәк. Шундый шартларга түзеп, сыналгач та сынмаганнар, әлбәттә, чын нефтьче булырга лаеклылар.

Чикләнгән җаваплылыктагы «Татнефть - Норлатнефтеразведка» җәмгыяте (элеккеге НУРБ) нәкъ шундый нефтьчеләре белән горурлана ала. Себер җирләрендә кара алтын эзләп, шул һөнәр ияләренең ниндиләрен генә күрмәгән предприятие директоры А.С.Насолдин да Норлат нефть бораулаучыларының, белгечләренең тәҗрибәләрен, осталыкларын югары дәрәҗәгә куя һәм зур хөрмәт хисе белән карый.

- Коллектив гаҗәеп көчле, теләсә нинди кыенлыкларны да яулый торган белгечләре күп. Бигрәк тә олы тәҗрибә туплаган производство технологлары белән коллектив мактана ала,- ди ул. Җитәкче сүзләрен түбәндәге факт та раслый: предприятиенең бораулау цехы 1995 елда региональ республикалар арасында үткәрелгән ярышта тикмәгә генә беренче урынны алмагандыр, мөгаен.

Аерым бригадалар хакында сүз чыкканда дистә еллар үзләрен кырыс хезмәткә багышлаган бригада җитәкчеләре Ю.Г.Газизов, М.Н.Хәсәншин, З.Х.Мостафин хакында җылы сүзләр генә әйтелә.

Шул бригадаларның берсе Зәмил Мостафинныкына тулырак тукталып киткәндә, кыен шартларда да аларның үз эшләрен җиренә җиткереп башкаруларын күрергә мөмкин. Зәмил нефть разведка бораулау идарәсенә технолог булып килгән иде, аннан инженер - технологка күтәрелде һәм атаклы нефтьче Михаил Федорович Ананьевның алдынгы бригадасына икенче мастер булып иреште. Хезмәт карьерасы аның белән тәмамланмый: мәрхүм Ананьевның уң кулы Зәмил Хәйдәрҗанович остазы тапшырган эстафетаны кулына ала һәм аны нык тота. Электән үк яңа сынау җайланмалары бораулауның катлаулы ысуллары ышанып тапшырылган бригада бүген шундый ук осталыгын, үткенлеген югалтмады. Бүгенге көндә алар Аксубай җирендә җир катламын бораулауда бик үзенчәлекле, авыр бирелә торган горизонталь бораулау ысулы белән эшлиләр. Март аена 1300 метр җир токымын тишеп үтәргә тиеш булсалар, алар аны 600 метрга арттырып үтәделәр. Бригадада күптәнге, зур тәҗрибәлә нефтьчеләр тупланган. Шуларның берсе бораулаучы Владимир Никитин үткән елда осталыгын күпләргә күрсәтте. Баштан предприятие бораулаучылары арасында ярышып беренчелекне яулый, аннары үткән елда Башкортостанда үткәрелгән республикаларның региональ конкурсында да сынатмый- призлы өченче урынны яулый. Бригадада бораулаучылар Анатолий Атоманов, Фаил Зәйнетдинов, бораулаучы ярдәмчеләре Александр Гордеев, Минсәгыйть Әхмәтшин, Николай Зимин, Әнвәр Галиуллин турында да мактау сүзләре генә әйтергә мөмкин. Шулай ук электр приборлары төзеклеген тикшерү буенча электромонтер Владимир Александров, слесарь Сергей Малышев, котельня операторы Минәхмәт Хәсәншин, су кудыручы Рифкать Рәхмәтуллин да үз эшләрен оста һәм инле башкаралар. Бригада бер гаилә сыман: дүртәр көн өйдән еракта иңгә - иң куеп эшләү аларның араларын якынайтадыр, мөгаен. Эштән бушагач, күңелле ял итә дә беләләр егетләр, төсле телевизор, видеомагнитофон алып куйганнар, шашка, шахмат уеннары белән мавыгалар. Аш - су остасы Татьяна Магина өйдәгечә тәмле итеп ашлар, ризыклар әзерли.

Иртәгесен тагын һәркем эш урынында: һәркайсы үз бурычын белә һәм җиренә җиткерергә тырыша.

Ф.ЗЫЯТДИНОВА.

## Савучы иде, мөдир булды

Валерий Григорьевич озак вакыт районда сыер савучы ир - атларның аз санлы исемлегендә йөрде. Тырышып эшләде, савучылар да шат иделәр: сөт тулы бидоннарны хатын - кызларның кулына да тидерми, һәрчак аларга ярдәмгә килә иде.

Күптән түгел хуҗалык җитәкчелеге Валерий Григорьевичның тырышлыгын искә алып, аны үзе эшләгән товарлыклы - сөтчелек фермасына мөдир итеп билгеләде. Максимов зур теләк белән керешти ул бу эшкә: хезмәтне дөрес оештыру, аның нәтиҗәлелеген күтәрү - төп максаты шундый мөдирнең.

**Рәсемдә: МСОның «Төзүче» ярдәмче хуҗалыгы ферма мөдире В.Максимов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**




**Акцияләр сатып алабыз:**

**«Газпром» РАҖ,**
**«Сургутнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл» НК АҖ,**
**«Татнефть» АҖнең**
**(Б категорияле),**
**«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,**
**«Юганскнефтегаз» АҖ,**
**«Пурнефтегаз» АҖ,**
**«ЕЭС России» РАҖ**
**акцияләрен сатып алабыз.**

**Бәяләр - иң кыйммәте.**

Адрес: Совет ур.,94,«Родина» кинотеатры, II кат., тел.: 2 - 23 - 10, 2 - 18 - 61, (эш көннәрендә иртәнге 8дән 16 сәгатькә кадәр, төшке ял 11.30 дан - 13 сәгатькә кадәр). ТР финанс министрлыгыннан бирелгән 72 нче номерлы лицензия.

# УҢЫШКА НИГЕЗ ЯЗДАН САЛЫНА

**Укып чык та куллан!**

## (Районда быелгы язгы кыр эшләрен үткәрүнең үзенчәлекләре)

***Район игенчеләре алдында быел гектардан уртача кимендә 35 центнер бөртекле ашлык, 250 центнер шикәр чөгендере алу, бер баш шартлы терлеккә кимендә 36 центнер азык берәмлеге күләмендә тупас һәм сусыл азыклар әзерләү бурычы тора.***
***Ә моңа нигез бүген - язгы кыр эшләре чорында салына.***

**Бу чорда төп бурыч җирдә дымны күбрәк туплап, аның саклынышын һәм бәрәкәтле файдаланылуын тәэмин итүдән гыйбарәт. Хәзер көн саен гектардан 40 - 60 тонна дым парга әйләнә. Шуңа күрә дә барлык чылбырлы тракторлар да тәүлек буе файдаланылырга, туфрак эшкәртүдә киң алынлы агрегатлар мөмкин кадәр күбрәк кулланылырга тиеш.**

### Уҗым культураларын

**иртә яздан азотлы ашламалар белән тамырдан тукландыру үткәрү шарт.** Исәпләүләр азотның тәэсир итүчән матдәдә гектарга кимендә 70 килограмм булырга тиешлеген, ә азотның һәр килограммы 15 килограмм өстәмә уңыш бирүен күрсәтә.


**Уҗым басуларына өстәп чәчүне иң иртә срокларда, пычрак беткәнче үк һәм бары тик арпа орлыгы белән генә үткәрергә кирәк.** Чәчү нормасы бер гектарга 150 килограмм (3,5 миллион бөртек). Бер квадрат метрда 450дән дә ким үренте яки 200 дән дә ким үсенте булган уҗым чәчүлекләре гектардан 20 центнердан да күбрәк уңыш бирмәячәк. Уҗымнарны тырмалау өстәмә чәчү, тукландыру һәм райтырмалар белән тырмалау белән бергә алып барылырга тиеш.

### Күпьеллык үләннәргә

**килгәндә, алардан быел нигездә люцерна һәм клевер орлыгы һәм бары тик капламсыз гына чәчү шарт.**

Люцернаны орлыкка бары тик киң рәтле ысул белән генә чәчү кирәк. Күпьеллык үлән чәчүлекләрен дүрт елдан да озаграк файдаланырга ярамый. Бер квадрат метрда 110 - 120дән дә кимрәк үсемлек калган кырларны, аларның соңгы тапкыр кайчан чәчелгән булуына да карамастан, калдырырга кирәкми.

**Үләннәрне тамырдан тукландыру шарт.** Кыяклыларның гектарына 5 центнер азотлы ашлама, кузаклыларга - составында тәэсир итүчән матдәдә 60 ар килограмм азот һәм калий, 40 килограмм - фосфор булган ашламалар кулланырга кирәк. 1 - 2 еллык чәчүлекләрне гадәти тырмалар белән ике эздән, шулай ук БИГ - 3, БМШ - 15 тырмалары белән тырмалау, 3 елдан «картрак»ларын лущильниклар белән эшкәртү шарт. Шуның артыннан ук су сиптерә башларга кирәк.



### Сабан культуралары

**Быел сабан бодаена аерым игътибар бирергә кирәк - ул бөртеклеләрнең 60 процентын алып торачак.** Аны иң уңдырышлы, чүп үләннәрдән азат участокларга урнаштыру мөһим. Чәчү алдыннан һәм чәчкәндә рәтләргә тулы дозада минераль ашлама кертү зарур. Орлыкнң **Люба, Приокская, Красноуфимская - 90** кебек көчле һәм кыйммәтле сортларын кулланырга. Чәчүгә иң иртә срокларда керешү, аны аркылыга - буйга яки эзгә - эз чәчү кирәк. Аркылыга - буйга чәчкәндә озын буйда технологик эз калдыру мәҗбүри. Моның өчен өч чәчкечле агрегатның уртадагы чәчкеченең 6,7 һәм 18, 19 нчы орлык төшерү аппаратларын ябып куясы.

### Туфрак эшкәртү

өчен киң алымлы **КБМ - 10, КФН - 8,5** культиваторларын, СГ - 21 таккычы белән агрегатланган ВНИИССР тырмаларын кулланырга, туңга сөрелгән җирне чәчү алдыннан тырмалап тормаска. Бу чәчүне иртәрәк үткәрергә, туфракта дымны күбрәк саклап калырга, тракторларны җитештерүчәнрәк файдаланырга һәм ягулыкны янга калдырырга мөмкинлек бирәчәк.

### Чәчү алдыннан

**орлыкларны агуларга,** бер үк вакытта ЖУСС, ЖНУ һәм башкаларны кулланып һәм микроэлементлар кушып ТМТД-80, фенорам препаратлары белән **инкрустацияләргә** кирәк. Барлык чәчүлек материал да 1000 орлыкның массасы 35 граммнан да ким булмаслык иттереп калибрланырга тиеш. Аркылыга - буйга чәчкәндә чәчү нормасы 15 процентка артуын, ягъни 7,5 миллион бөртеккә җитүен исәпкә алсак, бер гектарга чәчеләсе орлыкның авырлыгы 300 килограмм тирәсе булырга тиеш.

### Шытымнар чыгып беткәч

чәчүлекләрне азотлы ашламалар белән тукландыру һәм гербицидлар белән эшкәртү шарт. Соңгысын француз бөркегечләре ярдәмендә технологик эз буш буенча кертәләр. Бу очракта агрегат 21,6 метр алынлы итеп көйләнә, форсунканы ябып бер эз буш калдырып барыла. Монда янәшә эзләрдә гербицидның бер урынга ике тапкыр сибелүенә юл куярга да, бер буйга сибелмичә калдырырга да ярамый. Икенче тапкыр эшкәрткәндә агрегатны башка эзләрдән йөртәләр.

Кирәк булганда үсемлекләр шыткач җиңел тырмалар белән тырмаларга мөмкин.

**Бөртеккә һәм силоска игеләчәк**

### кукуруз -төп азык культурасы

Быел аны бөртек өчен 10 мең, силоска дип 5340 гектарда чәчәргә уйлыйбыз. Ике очракта да кукуруз тулысынча өлгергәч бөртеккә, балавызсыман өлгерештә силоска җыеп алу максатыннан бары тик бөртек технологиясе буенча гына игәргә кирәк. Орлыкка иртә өлгерешле **Скандия, Нарт - 150, Эпсон** һәм башка сортлар, силоска **беренче икесеннән тыш Коллективный - 181** һәм башка бөртек гибридлары кулай.

Бөртеккә һәм силоска кукурузны бодай кебек үк иң иртә срокларда чәчәсе. Чәчү нормасы - бөртек өчен бер погон метрга 6, силос максатларында 8 үсенте булдыру. Ашлама микъдарын гектардан 70 центнер бөртек, 350 центнер силос массасы алырлык итеп исәпләргә кирәк.

**Терлек азыгы максатларында бөртеклеләрдән арпага, кузаклылардан борчакка өстенлек бирергә кирәк.** Шунысы да бар, арпага, барлык башка бөртекле культураларга кулланылган төп ашламалардан тыш тагын гектарына 50 килограмм тәэсир итүчән матдә исәбеннән фосфор бирү мәҗбүри. Рәтләргә кертелгән фосфорның килограммы иген уңышын 25 килограммга кадәр арттыра. Аннары, кайбер белгечләр борчак үзе азот туплаучы культура булгач, ул культура астына азот кертү мәҗбүри түгел дип исәплиләр. Бу - ялгыш фикер. Үсешенең башлангыч чорында борчак азотка бик мохтаҗ була һәм рәтләргә нитрофосфат һәм башка катлаулы ашламалар кертү мәҗбүри. Бу культураларны игү технологиясенең башка элементлары гадәти.

Моңа кадәр безнең малларның рационында гадәттә аксым җитәрлек булмый торган иде. Чөнки соңгы елларда борчакны сенажга чәчми башладык. Шуңа күрә **быел 3700 гектарда сенажга дип махсус рәвештә һәм үзен генә борчак чәчеп, аны бөртек тутырган чорында яшел массасын ваклатмыйча гына җыеп алу күздә тотыла.** Игү технологиясе борчакны бөртеккә үстергәндәге кебек үк. Рәтләргә катлаулы ашламалар кертү мәҗбүри, чәчү нормасын гектарга шытым бирердәй 1,4 миллион бөртеккә кадәр җиткерү шарт.

### Берьеллык үләннәрдән

быел һәр хуҗалыкка сыер башына 0,4 гектар исәбенән **рапс һәм тары** катнашмасы чәчү заданиесе җиткерелде. Бер гектарга чәчү нормасы - 10 килограмм рапс + 20 килограмм тары. Моннан тыш, яшел азыкка калдырылган уҗым чәчүлекләрендә көтү йөртү туктатылганнан соң 2000 гектар чамасы җиргә рапс үзе генә дә чәчеләчәк.

**Печәнгә һәм сенажга вика - солы катнашмасы 2300 гектар мәйданда игеләчәк.** Виканы чәчү нормасы гектарга 60, солыныкы 120 килограмм. Моңда да рәтләргә минераль ашлама кертү мәҗбүри.

Шуңа игътибар итәргә кирәк, быел көнбагыш катыш азык катнашмалары чәчелмәячәк - анализ алардан рәтле азык чыкмаганлыгын күрсәтә.


### Шикәр чөгендере -

төп техник культура, безгә акча кеременең 20 процентына кадәрен шул бирә һәм аны аерым игътибар үзәгендә тоту кирәк. Быел аны 6560 гектар мәйданда игәргә ниятлибез. Әйбәт уңыш алу өчен гектарына кимендә 350 килограмм тәэсир итүчән матдә исәбеннән минераль ашламалар кертү мөһим. Районда бу культураны кул хезмәте кулланмыйча игү тәҗрибәсе бар инде. Моның өчен гербицидларны киң файдалану шарт. Чәчү алдыннан гектарга 5 килограмм исәбеннән эптам туфрак гербицидын кертергә кирәк. Шунысын да истән чыгарырга ярамый: керткәннән соң 15 минут эчендә ул гербицид туфракка күмдерелергә тиеш.

Чөгендерне кул хезмәте кулланмыйча игү технологиясенә өстенлек бирү мөһим. Районда орлыкны төгәл төшерә торган 28 чәчкеч бар. Тәҗрибә күрсәткәнчә, китмән белән эшкәрткәндә гектарда 70 - 80 меңнән артык үсенте калмый, ә кул хезмәте кулланмаганда бу күрсәткеч 110 - 120 меңгә җитә һәм бу уңышның 20 - 30 процентка күтәрелүен тәэмин итә.

**Теге яки бу культураны игү технологиясенә һәр белгеч иҗади якын килергә тиеш - бер үк төрле ике басу булмаган кебек, катгый калыплар да булырга мөмкин түгел. Шуңа күрә уңышны күтәрергә мөмкинлек бирә торган кечкенә генә мөмкинлекне дә кулланырга кирәк.**

**Ю.ТЕРЕНТЬЕВ,**
**район хакимияте башлыгының беренче урынбасары, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.**



# Авыл гына димәссең

Район кулланучылар җәмгыяте Урта Камышлыда төзегән «кичке кафе» нәкъ менә районыбызда кулланучылар кооперациясе хезмәткәрләренең республика семинары башланган көнне үзенең беренче клиентларын кабул итте. Искиткеч зәвык белән бизәлгән, 30 урынга исәпләнгән бу кафе авыл эшчәннәренә хезмәт күрсәтәчәк, шуңа да аның эш вакыты 18 сәгатьтән 23 сәгатькә кадәр - авыл кешесе бераз эштән бушап, тын алыр җае булгач билгеләнгән. Заманча җиһазланган бу сәүдә ноктасы авыл тормышына җанлылык, ялына бер бизәк өстәр дип уйлыйбыз.



**Рәсемдә: Яңа ачылган кичке кафеның эчке күренеше.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

*Шәһәр мәктәпләрендә татар телендә бәйрәмнәр, кичәләр, очрашулар үткәрү соңгы елларда традициягә әверелеп бара инде. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә оештырыла торган әлеге бәйрәмнәр бер яклап зур хезмәт, оештыру мәшәкате, түземлек һәм вакыт таләп итсәләр дә, икенче яклап эчкерсезлек белән сугарылган әдәби - мәдәни чара буларак, укучыларда милли үзаң һәм кызыксыну тәрбияләүдә нәтиҗәле эшчәнлек булып торалар.*

# Әбекәй-алтыным, минем иң якыным!

Ә менә шәһәрнең 4 нче мәктәп - гимназиясендә «Әбиләр бәйрәме» үткәрделәр, «Әбекәй алтыным, минем иң якыным!» дип аталган бу кичәгә мәктәп укучыларының шәһәрдә генә түгел, хәтта тирә - як авылларда яшәүче «иң якыннары» да җыелган иде. Ак яулыклы, аллы - гөлле яки ялтыр - йолтыр шәлъяулыклы әбиләр җыелган мәктәп залы җәйге чәчәкле һәм күбәләкле, җиләкле болынны хәтерләтә иде. Сәхнә түренә язылган назлы сәламләү сүзләре, чәчәкләр белән бизәлгән сәхнә үзе һәм залда яңгыраган моңлы көй күңелләрне нечкәртте. Әйтерсең лә шул минутларда бүгенге тынгысыз, мең дә берне белүче балалар белән гасыр сынауларын узган, хәзерге тормышның шау - шуында бераз аптырап һәм гаҗиз булып та калган сабыр әбиләребез арасында күзгә күренмәс асыл күпер - буыннар күпере сузылды.

Әбисе белән өйдә генә ярым - йорты татарча сөйләшә торган балалар өчен бигрәк тә тәэсирле булды бу очрашу. Чөнки алар әби теленең шушы якты бәйрәмдә төп хуҗа булуын күрделәр, аның яңгырашын залдан һәм сәхнәдән тыңладылар, үзләре шул туган телдә сөйләделәр һәм җырладылар, әбиләренең шул телдә гөрләшеп аралашуыннан бик тә канәгать калдылар. Укучыларның үз хезмәтләре - әбиләренә багышланган иншалар күргәзмәсе дә бу көнне тамашачыларның игътибар үзәгендә булды. Әмма барыннан да кызыгы - оныклары әбиләренең сәхнәдә чыгыш ясауларын тыңладылар һәм таң калдылар. Тәмле ашлар белән сыйлаучы, әти - әнидән каты сүз дә әйттермәүче, балдан татлы шушы оныкларының каникулларын санап - санап көтеп алучы бу әбиләр әле сәхнәгә чыгып җырларга да, бәет - мөнәҗәтләр көйләргә дә оста халык икән бит!



... Буыннар очрашуы менә шулай дәвам итте. Әллә вакыт, әллә игътибар, әллә тел байлыгы җитмәүдән әйтелмичә калган, күңелләрдә җыелып килгән, тыелып килгән кадерле сүзләр, моңлы көйләр бу көнне агылды да агылды. Мәктәп залына, мәктәп сәхнәсенә генә сыеп калмады ул, әбиләрнең милли күчтәнәчләре - чәкчәк - бавырсаклар, кош теле - җәймәләр куелган чәй табыны янына да күченде. Ә аннан соң әлеге эчкерсезлек, куанычлы халәт алтын әбекәйләр белән аларның гаиләләренә, өйләренә - яшәгән авылларына, шәһәребезнең төрле тарафына таралды.

***

***... Сер түгел, бүгенге көндә буыннар бәйләнеше гаять йомшарган чорда яшибез без. Милләтебезнең язмышын хәл итәчәк үсмер буын ярга ташланган балык хәлендә... Аның сулыйсы килә, әмма ул бу хәлендә сулый алмый, аның асылы моңа яраклашмаган!.. Бу буынның турыдан - туры терәге - таянычы булган ата - ана үзе дә икеле - микеле бер халәттә. Чөнки аларның күпчелеге үзләре дә милли тәрбиядән мәхрүм! Ә әбиләребез хәзергә безнең белән милләтебезнең үткәнен һәм киләчәген бәйләп торучы иң ышанычлы буын. Менә шушы катлаулы заманда шәһәребезнең 4нче рус - татар мәктәп - гимназиясендә оештырылган әлеге олуг бәйрәм бәяләп бетергесез кыйммәткә ия дә.***

***Бу мәктәптә милли тәрбия эшенең һәр тармагы, һәр юнәлеше максатчан итеп оештырыла һәм алып барыла. Монда мәктәп директоры Н.Ә.Насыйбуллинаның фатихасы, милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары Р.К.Вәлиеваның оештыру сәләте һәм татар теле һәм әдәбияты укытучыларының уртак тырышлыгы һәм хезмәте игътибарга, бәяләүгә лаек.***

***Мәктәп коллективының киләчәктә дә шушы кыйбланы югалтмауларын телисе һәм шуңа ышанасы килә.***

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА,**
**район мәгариф бүлеге мөдиренең милли мәсьәләләр буенча урынбасары.**

**Рәсемдә: әбиләр чәй өстәле янында.**
**Нина КВАШНИНА фотосы.**


# Котлыйбыз!

Чишмә авылында яшәүче ***әниебез Затия Төхвәтулла кызы һәм әтиебез Рәис Абдулла улы Насыйбуллиннарның*** *икесенә дә апрель аенда 59 яшь тулу уңаеннан кайнар котлыйбыз. Нык сәламәтлек, озын гомер телибез.*



***Иң изге теләкләр белән кызыгыз Рәзинә, улларыгыз Рөстәм, Рәхимҗан, киленегез Наилә, оныкларыгыз Рамил белән Илназ.***

Апрель аенда Урта Чаллыда яшәүче безнең өчен бик кадерле, зур ихтирамга лаек булган **әтиебез Минсәлим Мәсәлим улы Сөләймановка 60 яшь тулды.** Аны тормышындагы зур вакыйга уңаеннан ихластан котлыйбыз, киләчәк көннәренең дә сау - сәламәт булып, шатлык - куанычта үтүен, гаилә бәхете, әни белән бергәләп тигез, озын гомер кичерүләрен телибез. Һәрчак аларга бәхет юлдаш булсын, ә кайгы - хәсрәтләр алардан бик еракта йөрсен.



**Изге теләкләр белән тормыш иптәшең һәм бар булган балаларың.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

### Абонентлар игътибарына!

**Шәһәрара телефон элемтәсендә кодлар үзгәрде**

| | |
|---|---|
| **1. Әгерҗе - 8 - 855 - 51** | **9. Мамадыш - 8 - 855 - 68** |
| **2. Азнакай - 8 - 855 - 11** | **10. Менделеев - 8 - 855 -49** |
| **3. Актаныш - 8 - 855 -52** | **11. Минзәлә - 8 - 855 - 55** |
| **4. Әлмәт - 8 - 855 -12** | **12. Мөслим - 8 - 855 - 56** |
| **5. Баулы - 8 - 855 - 19** | **13. Яр Чаллы - 8 - 855 - 2** |
| **6. Бөгелмә - 8 - 855 - 14** | **14. Түбән Кама - 8 -855 -53** |
| **7. Алабуга - 8 - 855 -57** | **15. Сарман - 8 - 855 - 59** |
| **8. Зәй - 8 - 855 - 58** | **16. Урыссу - 8 - 855 - 10** |

### Сатабыз

**1985 елгы ВАЗ - 2104 (12,5 млн.).** Тел.: 5 - 15 - 98 (кичке 6нчы яртыдан соң).

***

**Сүтеп алу өчен әйбәт хәлдәге йорт.** Адрес: Космонавтлар ур., 20. Тел.: 5 - 29 - 53.

***

**«Алмалык» артында дача, «Урал» мотоциклы.** Тел.: 5 - 19 - 80 (кичке 5тән соң).

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2101**. Адрес: Школьная ур., 92 (кичке 5тән соң).

***

**Видеокамера, видеомагнитофон, гараж чанасы.** Тел.: 5 - 16 - 13.

***

**40 мең км. йөргән, А - 76 бензины белән эшли торган «Москвич - 412»**. Тел.: 2 - 24 - 57. (Көндезге 4тән соң).

**

**«Сюита» пианиносы**. Тел.: 5 - 25 - 78.

***

**Әйбәт хәлдәге «Муравей» 2м - 02 мотороллеры.** Адрес: К.Маркс проспекты, 7 - 4.

***

**ВАЗ - 2103.** Тел.: 5 - 11 - 93.

**Колхоз базарындагы «Альянс» кибете киң ассортиментта «Стинол», «Минск», «Атлант» суыткычлары, комбинированный газ мичләре тәкъдим итә (2 елга гарантия, Октябрь районында өйгә китереп бирәбез). Шәһәрдә иң арзан бәядән 3 мең исемдә аудио - видеокассеталар бар**. Тел.: 5 - 24 - 97, лицензиябез № 007565 / 1.

## Рәхмәт белдерәбез

Кадерле улыбыз Илгиз Шәфиевны җирләүдә матди һәм мораль ярдәм күрсәткән Югары Норлат авылы халкына, мәктәп коллективына, күршеләргә, туганнарга олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Шәфиевлар гаиләсе.**

## Рәхмәт белдерәбез

Ирем һәм әтиебез Роберт Салих улы Вәлиевны җирләүдә зур мораль һәм матди булышлык күрсәткәннәре өчен 48 нче янгын часте коллективына һәм шәхсән часть начальнигы И.И.Курамшинга, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе начальнигы Р.С.Хәмидуллинга, ателье мөдире Р.А.Усмановага, ДРСУ начальнигы Р.А.Газизуллинга, шул оешмаларның барлык хезмәткәрләренә, якыннарыбызга, туганнарыбызга, күршеләргә, танышларыбызга чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.

**Мәрхүмнең хатыны һәм балалары.**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә.